**МИНИСТЕРСТВО ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ УРМАН ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.05.2023 № 256-осн

Казан ш.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына караган урманчылыклар – Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләренең федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген раслау турында» 2021 елның 20 декабрендәге 694-осн боерыгына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының норматив хокукый актларын федераль законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына караган урманчылыклар – Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләренең федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген раслау турында» 2021 елның 20 декабрендәге 694-осн боерыгына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Исемлектә санап үтелгән вазыйфаи затларга урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нормаларына таянып эш итәргә.».

2. Юридик бүлек җитәкчесенә (Т.А. Барсукова) боерык имзаланган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек чорда аны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары И.Н.Зариповны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Р.Ә.Кузюров